КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 4 апрель г.Казань № 270

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Экология һәм табигый байлыклар министрлыгы мәсьәләләре» 2005 ел, 6 июль, 325 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы Экология һәм табигый байлыклар министрлыгы турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Экология һәм табигый байлыклар министрлыгы мәсьәләләре» 2005 ел, 6 июль, 325 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2009 ел, 24 февраль, 101 нче; 2009 ел, 9 ноябрь, 776 нчы; 2010 ел, 9 апрель, 253 нче; 2010 ел, 9 июнь, 454 нче; 2010 ел, 10 декабрь, 1038 нче; 2010 ел, 17 декабрь, 1078 нче; 2011 ел, 21 февраль, 125 нче; 2011 ел, 25 март, 220 нче; 2011 ел, 13 апрель, 291 нче; 2011 ел, 29 июль, 613 нче; 2011 ел, 13 август, 674 нче; 2012 ел, 8 июнь, 494 нче; 2012 ел, 30 июль, 646 нчы; 2013 ел, 9 февраль, 80 нче; 2013 ел, 14 март, 163 нче; 2013 ел, 7 октябрь, 730 нчы; 2013 ел, 30 ноябрь, 940 нчы; 2014 ел, 5 февраль, 64 нче; 2014 ел, 29 март, 201 нче; 2014 ел, 11 ноябрь, 853 нче; 2015 ел, 2 февраль, 49 нчы; 2015 ел, 3 июнь, 401 нче; 2015 ел, 20 август, 610 нчы; 2015 ел, 2 октябрь, 733 нче; 2016 ел, 26 февраль, 121 нче; 2016 ел, 25 ноябрь, 874 нче; 2017 ел, 9 февраль, 74 нче; 2017 ел, 10 июль, 468 нче; 2017 ел, 6 ноябрь, 846 нчы; 2017 ел, 30 ноябрь, 930 нчы; 2018 ел, 29 март, 185 нче; 2018 ел, 4 май, 317 нче; 2018 ел, 27 июнь, 523 нче; 2018 ел, 15 декабрь, 1140 нчы; 2019 ел, 16 гыйнвар, 9 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасы Экология һәм

табигый байлыклар министрлыгы турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3.3 пунктта:

3.3.1 пунктчада:

егерменче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«төбәк дәүләт экология күзәтчелегенә караган II һәм III категорияләргә кертелгән объектларда хуҗалык һәм (яки) башка эшчәнлек башкаручы юридик затлар һәм хосусый эшмәкәрләр тарафыннан тапшырыла торган җитештерү экология контролен оештыру һәм гамәлгә ашыру нәтиҗәләре турында хисаплар кабул итүне гамәлгә ашыра;»;

түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«төбәк дәүләт экология күзәтчелегенә караган II һәм III категорияләргә кертелгән объектларда хуҗалык һәм (яки) башка эшчәнлек башкаручы юридик затлар һәм хосусый эшмәкәрләр тарафыннан тапшырыла торган әйләнә-тирә мохитне саклау чаралары планын үтәү турында хисаплар кабул итүне гамәлгә ашыра.»;

3.3.7 пунктчага түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«төбәк дәүләт экология күзәтчелегенә караган II һәм III категорияләргә кертелгән объектларга әйләнә-тирә мохиткә пычраткыч матдәләрне вакытлыча агызуга рөхсәтләр бирә.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин